СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.06.2023 г.Зеленодольск № 119

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесе урынбасары Бауэр А. С. җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турындагы мәгълүматны тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәр Советы **карар кылды:**

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның түбәндәге өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1.1. физик затның вафат булган көненнән 3 ел үткәннән соң яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йәварисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

1.2. салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән алып өч ел вакыт узгач;

1.3. гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән өч еллык срокның тәмамлануы.

2. «Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»» 2013 елның 14 ноябрендәге 198 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үзенең гамәли көчен тарата.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ